**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 55-0-43, факс 55-0-43

# КАРАР

**20 ноябрь 2019 ел** **№ 4**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Кушкуй торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

2019 елның 4 декабрендә 11 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Кушкуй авылы Ленин ур 26 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Кушкуй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Кушкуй торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Кушкуй авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;

- Кушкуй авылында урамнарны яктырту максатыннан энергия саклаучы лампалар сатып алу һәм урнаштыру;

- Кушкуй авылында сулыкка керү юлын (пирс) төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге башлыгы Т.А. Хакимов**